# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

27 август 2019 ел №12

Каенсар авыл җирлеге Советы 2014 елның 20 нчы январе 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара районы прокурорының 2019 елның 14 июнендәге 02-01-22-2018 номерлы, ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатыннан, норматив хокукый актны үзгәртү турындагы таләбен карап, Каенсар авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Каенсар авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган (Каенсар авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 38 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 16 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 3 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту Кагыйдәләре белән территориаль зоналарны яисә аларның өлешләрен өстәмә юнәлешләр буенча куллануга аерым шәһәр төзелеше таләпләре билгеләнә:».

Каенсар авыл җирлеге башлыгы: И.А.Мифтахов.